251

# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

## Җир асты байлыклары турында

Закон җир асты байлыкларыннан файдаланганда, аларны бүлгәндә һәм биләгәндә килеп чыга торган мөнәсәбәтләрне җайга сала. Закон түбәндәге үзенчәлекләргә нигезләнә:

җир асты байлыкларыннан нәтиҗәле һәм комплексלы файдалану;

казылма байлыклардан файдалану мөнәсәбәтләрен җайга салу өлкәсендә хакимиятнең республика һәм җирле органнары вазыйфаларын чикләү;

җир асты байлыклары милекчеләренең һәм алардан файдаланучыларның хокукларын яклау;

җир асты байлыкларын куллану эшләренең иминлеген тәэмин итү.

### I бүлек. Төп төшенчәләр

1 статья. Татарстан Республикасының җир асты байлыклары

/1/ Татарстан Республикасының җир асты байлыклары туфрак - үсемлек катламы астында, елга-күлләр, сусаклагычлар төбендә урнашкан, өске катламга чыгарырлык, геологик өйрәнүләр һәм үзләштерүләр алып барырлык тирәнлектәге файдалы казылмалардан торган табигый тирәлекнең бер өлешен тәшкил итә.

/2/ Җир асты байлыклары Татарстан Республикасы милке була. Аларга шәхси милекчелек рөхсәт ителми.

/3/ Татарстан халкы исеменнән җир асты байлыкларын биләүгә, куллануга һәм бүлүгә хокук Татарстан Республикасы Югары Советына бирелә, ул җир асты байлыкларына хуҗа булуны республика Хөкүмәтенә яисә шуңа махсус вәкаләте булган органнарга тапшыра ала.

2 статья. Җир асты байлыклары турында законнар

/1/ Җир асты байлыклары турында Татарстан Республикасы законнары Татарстан Республикасы Конституциясеннән, әлеге Законнан һәм Татарстан Республикасының шуларга нигезләнеп кабул ителгән башка закон актларыннан гыйбарәт.

/2/ Әлеге Закон Татарстан Республикасы территориясендә үз көчендә була, һәм җирле администрациянең норматив актлары аңа каршы килергә тиеш түгел.

/3/ Җир асты байлыкларыннан файдаланганда җирдән, елгасулардан, үсемлек һәм хайваннар дөньясыннан, атмосфера һавасыннан файдалану һәм аларны саклау белән бәйле мөнәсәбәтләр Татарстанның тиешле законнары нигезендә җайга салына.

3 статья. Казылма байлыклардан файдалану мөнәсәбәтләре

/1/ Җир асты байлыкларын биләүдә, бүлүдә, файдалануда килеп чыга торган мөнәсәбәтләр казылма байлыклардан файдалану мөнәсәбәтләрен тәшкил итә.

/2/ Җир асты байлыкларының милекчеләре, җир асты байлыкларыннан файдаланучылар казылма байлыклардан файдалану мөнәсәбәтләренең субъектлары булалар.

/3/ Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең һәм дәүләт идарәсенең органнары, шулай ук халык депутатларының җирле Советлары, җирле администрация җир асты байлыкларыннан файдаланучылар була алмыйлар.

/4/ Җир асты байлыкларыннан файдаланучыга әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә бирелгән җир кишәрлеге казылма байлыклардан файдалану мөнәсәбәтләренең объекты була.

/5/ Казылма байлыклардан файдалану мөнәсәбәтләрен китереп чыгаручы актлар - әлеге Закон нигезендә бирелүче лицензия һәм җир кишәрлеге бирү турында акт ул.

/6/ Лицензия - билгеләнгән вакыт дәвамында һәм, лицензиядә килешенгән шартларны үтәгән килеш, бүлеп бирелгән кишәрлек чикләрендә җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын раслаучы документ ул.

/7/ Җир кишәрлеге бирү турында акт - җир асты байлыкларыннан файдаланучыларга лицензиядә күрсәтелгән максатларда җир кишәрлеге чикләрендә эшчәнлек алып баруга хокукын раслаучы таныклык ул.

/8/ Җир асты байлыкларыннан файдалану буенча дәүләт идарәсе Татарстан Хөкүмәте тарафыннан һәм моңа вәкаләтле башка органнар аша гамәлгә ашырыла.

4 статья. Милекчелек хокукының объектлары

/1/ Татарстан Республикасы милкенә түбәндәгеләр керә:

1/җир асты байлыклары һәм андагы файдалы казылмалар чыганаклары;

2/Татарстан Республикасы территориясендә һәм чиктәш территорияләрнең Татарстан территориясенә караган өлешләрендәге файдалы казылма чыганаклары;

3/ республика тарафыннан башка административ территорияләр чикләрендә, БДБнең милли дәүләтләре чикләрендә һәм чит илләрдә сатып алынган файдалы казылмалар чыганаклары, җир асты байлыклары кишәрлекләре;

4/ җир асты байлыкларының геологик төзелеше һәм минераль чимал мөмкинчелекләре турында дәүләт бюджеты исәбеннән алынган белешмәләр;

5/ бер уңайдан чыгарыла торган тау токымнарының ачык өемнәре һәм файдалы казылмаларны чыгарганда, баетканда һәм эшкәрткәндә җыела торган минераль чималның техноген ресурсларын барлыкка китерүче башка калдыкларны саклау урыннары.

5 статья. Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы

/1/ Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы, милек рәвешләренә карамастан, юридик һәм физик затларга, шулай ук башка дәүләтләрнең җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы турында лицензия алган юридик затларына һәм гражданнарына бирелә.

/2/ Әгәр җир куенындагы казылма байлыклардан файдалануга хокук турында лицензия бирелмәгән булса, әлеге җирдән файдалануга бирелгән хокук кына җир асты байлыкларын сәнәгатьтә эшкәртүгә хокук бирми.

/3/ Җир биләүчеләр үз мәйданнары чикләрендә үз ихтыяҗлары өчен, әмма сәүдә итү рөхсәтеннән башка, ачык юл белән, бораулау - шартлатү эшләрен кулланмыйча, 3 метр тирәнлеккә кадәр киң таралган файдалы казылмаларны чыгарырга хаклылар.

6 статья. Файдалы казылмаларны киң таралганнар рәтенә кертү тәртибе

/1/ Файдалы казылмаларны киң таралганнар рәтенә кертү Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан башкарыла.

7 статья. Казылма байлыклардан файдалану мөнәсәбәтләрен җайга салу өлкәсендә Татарстан хакимиятенең һәм идарәсенең республика органнары вәкаләтләре

/1/ Казылма байлыклардан файдалану мөнәсәбәтләрен җайга салу

өлкәсендә Татарстан хакимиятенең һәм идарәсенең республика органнары карамагында түбәндәгеләр була:

1/ республиканың җир асты байлыкларын геологик өйрәнү буенча республиканың дәүләт программаларын төзү һәм аларны гамәлгә ашыру;

2/ республика территориясендә һәм читтән алынган мәйданнарда казылма байлыкларны бүлү – җир асты байлыкларыннан файдалану хокукына лицензия бирү.

3/ республика территориясендә һәм читтән алынган мәйданнарда җир асты байлыкларыннан нәтиҗәле файдалануның бердәм тәртибен ачыклау, казылма байлыкларны чыгару белән бәйле булмаган җир асты байлыкларын куллануны һәм казылма байлыкларны геологик өйрәнүне, казылма байлыкларны эшкәртүне дәүләт тарафыннан тикшерүнең һәм күзәтүнең бердәм системасы буенча һәм җир асты байлыкларын саклау буенча положениеләр билгеләү;

4/ җир асты байлыкларын куллану өчен түләүләр һәм түләүләрне тотып калу тәртибен билгеләү;

5/ Татарстан Республикасының Геологик мәгълүматлар буенча бердәм фондын төзү, дәүләт бюджеты исәбеннән алынган мәгълүматларга хуҗа булу;

6/ республика бюджеты исәбеннән финансланучы җир асты байлыкларын файдалану белән бәйле фәнни- тикшерену һәм тәҗрибәконструкторлык эшләрен җайга салу;

7/ җир асты байлыклары турындагы законнарны камилләштерү;

8/ казылма байлыклар запасларының дәүләт нисбәтен /балансын/ төзү;

9/ гадәттән тыш очракларда һәм әлеге территория халкы мәнфәгатьләрендә Татарстан Республикасы Югары Советы игълан иткән

җирле референдум карары нигезендә генә файдалы казылмаларны өйрәнү һәм эшкәртү өчен җир кишәрлекләрен тапшыру;

10/ җир асты байлыкларын геологик өйрәнү буенча эшләрне дәүләт тарафыннан теркәү;

11/ файдалы казылмаларның чыганаклары һәм аларны билгеләү кадастрын төзү;

12/ файдалы казылмаларны чыгару белән бәйләнмәгән җир асты корылмаларын төзү өчен файдаланыла торган җир асты мәйданнарын дәүләт исәбенә алу;

13/ киң таралган файдалы казылмаларның исемлеген ачыклау;

14/ файдалы казылмаларның запаслары һәм ресурслары, җир асты байлыкларының кыйммәтен билгеләүче үзенчәлекләре турында-гы материалларга дәүләт экспертизасы үткәрү;

15/ куркынычсызлыкны тәэмин итү һәм тирәяк мохитне саклау йөзеннән, аерым мәйданнарда җир асты байлыкларыннан файдалануга чикләүләр кертү;

16/ җир асты байлыкларын куллану һәм саклау буенча халыкара килешүләр төзү;

17/ җир асты байлыкларын өйрәнү, куллану һәм саклау өлкәсендә башка мәсьәләләрне җайга салу.

8 статья. Казылма байлыклардан файдалану мөнәсәбәтләрен җайга салу өлкәсендә халык депутатларының район һәм шәһәр Советлары вәкаләтләре

/1/ Казылма байлыклардан файдалану мөнәсәбәтләрен җайга салу өлкәсендә халык депутатларының район /шәһәрләрдәге районнардан гайре/ һәм шәһәр Советлары карамагында түбәндәгеләр була:

1/ территориядәге халыкның җәмгыяви-икътисадый мәнфәгатьләрен кайгырткан килеш һәм җир кишәрлекләрен бирү белән бәйле

рәвештә, җир асты байлыкларын кулланылышка тапшыру турындагы мәсьәләләрне хәл итүдә катнашу;

2/ файдалы казылмаларны сәнәгатьтә эшкәртү белән бәйле булмаган хуҗалык һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен җир асты байлыкларыннан, шул исәптән җир асты суларыннан файдалануның һәм зарарлы калдыкларны күмүнең тәртибен билгеләү;

3/ киң таралган файдалы казылмаларны чыгарганда һәм файдалы казылмаларны чыгару белән бәйле булмаган җир асты корылмалары төзегәндә җир асты байлыкларыннан файдалануны һәм аларны саклауны тикшерү;

4/ торак пунктлары, шәһәр яны зоналары, сәнәгать, транспорт һәм элемтә объектлары территорияләрендә җир асты байлыкларыннан файдалану очракларында кешеләрнең тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч яналса, хуҗалык объектларына яисә тирә-як мохиткә зыян килә торган булса, җир асты байлыклары мәйданнарыннан файдалануга чикләүләр кертү.

## II бүлек. Җир асты байлыкларыннан файдалану тәртибе

9 статья. Җир асты байлыкларыннан файдалануның төрләре

/I/ Җир асты байлыклары кулланылышка түбәндәге максатларда бирелә:

1/ тикшерүләр - геологик өйрәнүләр /геологик, геологик-экологик, гидрогеологик харитага /картага/ төшерү, эзләнүләр, казылма байлыкларның чыганакларын эшләү/ өчен;

2/ файдалы казылмаларның чыганакларыннан файдалану - төзекләндерү һәм файдалы казылмаларны чыгару өчен;

3/ файдалы казылмалар чыганакларын эшкәртү, транспорт тоннельләрен төзү, нефть, газ һәм башка матдәләрне җир астында саклау өчен, агулы матдәләрне, җитештерү калдыкларын күмү, агып төшә торган сулар өчен, дәүләтнең һәм җәмгыятьнең файдалы казылмалар чыганакларын эксплуатацияләү белән бәйләнмәгән башка ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен, җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен;

4/ фәнни, мәдәни, эстетик, санитария-сәламәтләндерү һәм башка /фән һәм укыту полигоннары, геологик тыюлыклар, табигать тыюлыклары, һәйкәлләре, мәгарәләр һәм башка җир асты куышлыклары/ әһәмияткә ия булган,махсус саклауны таләп итә торган геологик объектлар төзү өчен;

5/ минералогик, палеонтологик һәм башка геологик туплама /коллекция/ материалларын җыю өчен.

/2/ Җир асты байлыклары бер үк вакытта геологик өйрәнүләр /эзләнүләр, тикшерүләр/ һәм файдалы казылмаларны чыгару өчен дә кулланылышка тапшырылырга мөмкин. Бу очракта файдалы казылмаларны чыгару геологик өйрәнүләр вакытында да, шулай ук өйрәнүләр тәгәлләнгәч тә дәвам итәргә мөмкин.

/3/Җир асты байлыкларыннан файдалануның барлык төрләре проектларга, технологик сызымнарга нигезләнеп хәл ителә.

/4/ Моңа кадәр эшкәртелмәгән чыганаклар файдалануга конкурс яисә аукцион нигезендә тапшырыла.

<u>10 статья.</u> Җир асты байлыкларын тикшерүләр өчен тапшыру

/1/ Геологик өйрәнүләр өчен җир асты байлыклары мәйданнары лицензия нигезендә тапшырыла. Аларга җир кишәрлеге статусы бирелми. Геологик өйрәнүләр өчен тапшырылган җир асты мәйданнары чикләрендә

бер үк вакытта берничә тикшерүче эш алып барырга мөмкин. Аларның үзара мөнәсәбәтләре лицензия биргәндә ачыклана. Лицензиядә мондый язма булмаган очракта, эшләр алып баруга өстенлекле хокук лицензия бирелү көненә карап билгеләнә.

11 статья. Файдалы казылмаларның чыганакларын эксплуатацияләү өчен җир асты мәйданнарын тапшыру

/1/ Файдалы казылмаларның чыганакларын эксплуатацияләү өчен җир асты мәйданнары кулланылышка лицензия һәм җир кишәрлеген раслаучы акт нигезендә тапшырыла. Лицензия һәм җир кишәрлеген тапшыру турында акт бирү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Югары Советы тарафыннан расланган тиешле положениеләр белән билгеләнә.

/2/ Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы турында лицензия турыдан-туры сөйләшүләр нигезендә, конкурслар, аукционнар нигезендә тапшырыла.

/3/ Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы турында лицензияләр үзләренең элеккеге устав вазыйфалары аркасында элек беркетелгән территорияләрдә җир асты байлыкларыннан файдаланучы гамәлдәге дәүләт предприятиеләре /берләшмәләре/ тарафыннан турыдан-туры сөйләшүләр нигезендә бирелә.

/4/ Каты казылма байлыкларның чыганаклары сәнәгати үзләштерүләр өчен бары тик запаслар тикшерелгән һәм расланган очракта гына тапшырыла.

/5/ Лицензия һәм җир кишәрлеге алган җир асты байлыкларыннан файдаланучыларның әлеге Закон нигезендә җир кишәрлеге чикләрендәге җир асты байлыкларыннан файдаланырга тулы хокуклары бар. Башка юридик һәм физик затларның шушы җир кишәрлегендәге, шулай ук

җир асты байлыкларының лицензия белән билгеләнгән мәйданнары чикләрендә җир асты байлыкларын куллану белән бәйле эшчәнлекләре лицензия хуҗасының ризалыгы белән гамәлгә ашырылырга мөмкин.

/6/ Җир кишәрлегеннән читтә җир асты байлыкларыннан файдалану тыела.

/7/ Закон белән саклана торган табигать объектларындагы һәм территорияләрдәге җир асты байлыкларыннан файдалану Татарстан Республикасы законнары нигезендә, әлеге объектларның һәм территорияләрнең статуслары белән билгеләнә.

12 статья. Файдалы казылмаларны чыгару белән бәйле булмаган максатлар өчен җир асты мәйданнарын тапшыру

/1/ Файдалы казылмаларны чыгару белән бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен җир асты мәйданнарыннан файдалану хокукы турында лицензия тикшеренүләр алып барыла торган тирәнлеккә кадәр файдалы казылмалар табылмаган перспективасыз җир асты мәйданнары чикләрендә бирелергә мөмкин.

/2/ Файдалы казылмаларны чыгару белән бәйле булмаган максатларда, агулы матдәләрне һәм җитештерү калдыкларын күмү, агып төшә торган суларны агызу өчен җир асты мәйданнарын файдалану хокукы турында лицензия Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә проектларның дәүләт экспертизасы нигезендә гамәлгә ашырыла.

/3/ Җир асты байлыкларын кулланучылар үзләренең хуҗалык һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен тау кишәрлеге чикләрендә җир асты мәйданнарыннан файдаланырга хаклы.

13 статья. Җир асты байлыкларыннан файдалану чоры

/1/ Җир асты байлыкларыннан файдалану чоры лицензия нигезендә

билгеләнә һәм җир асты байлыкларын файдалану хокукы бирелгән көннән исәпләнелә, әмма тәгаен бер лицензия өчен түбәндә күрсәтелгән вакыттан да арта алмый:

- җир асты байлыкларын геологик өйрәнүләр өчен - 5 ел;
- файдалы казылмаларны чыгару белән бәйле булмаган максатларда файдалы казылмаларны чыгару өчен - 20 ел;
- җир асты байлыкларын геологик өйрәнүне һәм казылма байлыкларны чыгаруны берүүк вакытта гамәлгә ашыру өчен - 25 ел.

/2/ Файдалы казылмаларны чыгару белән бәйле булмаган җир асты корылмаларын, махсус саклана торган объектларны төзү һәм эксплуатацияләү өчен җир асты мәйданнарыннан файдалану чикләнмәгән вакытка бирелергә мөмкин.

/3/ Җир асты байлыкларыннан файдалану вакыты алардан файдаланучыларның таләпләре буенча озайтылырга мөмкин.

14 статья. Җир асты байлыкларыннан файдаланучыларның төп хокуклары һәм бурычлары

/1/ Җир асты байлыкларыннан файдаланучылар түбәндәге хокукларга ия:

1/ үзенә бирелгән җир асты мәйданында эшкуарлык эшчәнлегенең законнарга каршы килми торган төрле рәвешләрен һәм лицензиядә күрсәтелгән тиешле максатларын сайлау;

2/ лицензиядә башкасы каралмаган булса, үзләренең җир кишәрлекләрендә файдалы казылмаларны чыгару һәм аларны эшкәртү белән бәйле калдыкларны куллану;

3/ үзенә бирелгән җир кишәрлеге чикләрендә җир асты байлыкларын геологик өйрәнүне өстәмә рөхсәтләрдән башка гына шәхсән үз хисабына башкару;

4/ лицензиянең гамәли вакытын озайтуда башка дәгъвачылар

арасында өстенлекләрдән файдалану;

5/ лицензия бирелгән вакыт белән чагыштырганда шактый үзгәргән вакыйгалар килеп туганда, лицензия шартларын яңадан карау хакында лицензия бирүче органнарга мөрәҗәгать итү.

/2/ Җир асты байлыкларыннан файдаланучылар законнар нигезендә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

1/ лицензиядә билгеләнгән шартларны үтәүне;

2/ җир асты байлыкларыннан нәтиҗәле, комплексли файдалануны, шул исәптән аларны саклауны, аларны геологик өйрәнүнең бөтенлеген һәм җир асты байлыкларын эксплуатацияләү барышында запасларны эшкәртүнең бөтенлеген;

3/ эшләрне алып бару технологиясе, тирә-як мохитне саклау һәм җир асты байлыкларыннан файдаланганда куркынычсызлык техникасы буенча кабул ителгән нормаларны һәм кагыйдәләрне үтәүне;

4/ геологик, маркшейдер эш кәгазьләрен һәм эшләрне алып бару технологиясендә каралган башка төрле эш кәгазьләрен алып баруны һәм аларның сакланышын тәэмин итүне;

5/ Татарстан Республикасының Геологик мәгълүматлар фондына геологик мәгълүматлар яисә аның хакында белешмәләр бирүне;

6/ җир асты мәйданнарында эзләнелгән, аннан чыгарылган һәм анда калдырылган файдалы казылмаларның запаслары, алардагы компонентлар турында, файдалы казылмаларны чыгаруга бәйле булмаган максатларда җир асты байлыкларыннан файдалану турында мәгълүматларны Татарстан Республикасының Геологик мәгълүматлар фондына һәм дәүләтнең статистика органнарына тапшыруны;

7/ техноген калдыкларны зарарсызландыру һәм гамәлдән чыгаруны;

8/ җир асты байлыкларыннан файдалану белән бәйле булмаган эшләр алып барыла торган зоналарда атмосфера һавасын, җирләрне,

урман- суларны, үсемлек һәм хайваннар дөньясын, табигый тирәлектәге башка объектларны саклауны;

9/ файдалы казылмаларның чыганакларын эшкәртүдә һәм /яисә/ башка хуҗалык максатларында файдаланырлык өйрәнелгән казылма байлыкларның эшкәртелмәләренең һәм бораулау скважиналарының саклануын; файдаланылмый торган тау эшкәртелмәләрен һәм бораулау скважиналарын билгеләнгән тәртиптә юкка чыгаруны;

10/ җир асты байлыкларыннан файдалану белән бәйле эшләрнең зарарлы тәэсиреннән тыюлыкларны, табигый, тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне саклауны;

11/ кулланганда бозылган җир мәйданнарын билгеләнгән тәртиптә имин халәткә китерүне (рекультивация).

15 статья. Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктатырлык сәбәпләр

/1/ Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы түбәндәге сәбәпләр аркасында туктатыла:

- лицензиянең гамәли вакыты беткәч;

- лицензия хуҗасы җир асты байлыкларыннан файдалану хокукыннан баш тартса;

- җир асты байлыклары кулланылышка бирелгән предприятиеләр бетерелгәндә.

/2/ Әгәр файдаланучы:

- лицензиядә күрсәтелгән вакытта җир асты байлыкларыннан файдалануга керешмәсә;

- җир асты байлыкларын тиешле максатларда кулланмаса;

- җир асты байлыкларын файдалануның лицензиядә күрсәтелгән шартларын бозса;

- казылма байлыклар чыганакларын эшкәртүнең расланган проектындагы төп положениеләрне үтәмәсә;

- халыкның сәламәтлегенә һәм тирә-як мохитнең иминлегенә ачыктан-ачык куркыныч тудырса,-

җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы вакытыннан элек туктатылырга мөмкин.

/3/ Гадәттән тыш хәлләр /табигый бәла-казалар, сугыш хәрәкәтләре һ.б.лар/ килеп чыкканда, җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләр турында законнары нигезендә туктатыла.

I6 статья. Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктату тәртибе

/I/ Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы түбәндәге очракларда туктатыла:

I/ бу турыда карар кабул ителгәннән соң, җир асты байлыкларыннан файдаланучының язмача хәбәре белән I5 статьяның беренче өлешендә күрсәтелгән сәбәпләр аркасында;

2/ җир асты байлыкларыннан файдаланучы тарафыннан ясалган хаталар һәм аларны бетерү буенча аның тарафыннан чаралар күрелмәве хакында язмача хәбәр алганнан соң өч ай вакыт үткәч I5 статьяның икенче өлешендә күрсәтелгән сәбәпләр аркасында җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктату турында карар кабул ителергә мөмкин.

/2/ Әгәр җир асты байлыкларыннан файдалану җир асты байлыкларыннан файдаланучы гаебе яисә теләге белән туктатылса, җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы вакытыннан алда туктатылганда, предприятиенең эшен вакытлыча туктатуга яисә аны ябуга

киткән чыгымнар җир асты байлыкларыннан файдаланучы өстендә кала.

/3/ Әгәр җир асты байлыкларыннан файдаланучы предприятиенең гаебе булмыйча, җир асты байлыкларыннан файдалану дәүләт тарафыннан туктатылса, җир асты байлыкларыннан файдаланучы предприятиенең эшен вакытлыча туктатып торуга һәм аны ябуга киткән чыгымнарны дәүләт үз өстенә ала.

/4/ Дәүләтнең һәм җәмәгатьчелекнең башка ихтыяҗлары өчен җир асты байлыклары мәйданнарын тартып алу кирәк булганда, җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын вакытлыча туктатып тору Татарстан Республикасы территориясендәге гамәлдәге законнар нигезендә Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан вәкаләт тапшырылган органның яисә урындагы затның гаризасы буенча суд тәртибендә башкарыла. Җир асты байлыклары тартып алынучы затка салынган зыяннарны һәм югалтуларны кире кайтару Татарстан Республикасы Хөкүмәтенә йөкләтелә.

<u>I7 статья.</u> Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктату турында карарларга шикаять белдерү тәртибе

/I/ Җир асты байлыкларыннан файдаланучы шушы хокукын туктату, туктатып тору яисә чикләү турындагы карар белән килешмәсә, ул карарга административ яисә суд тәртибендә шикаять белдерә ала.

<u>I8 статья.</u> Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын кире кайтару

/I/ Әгәр җир асты байлыкларыннан файдалануны туктатып торуны яисә чикләүне китереп чыгара торган сәбәпләр бетерелсә, кулланучының гаебе булмаса, лицензиянең гамәли вакытын туктатылып торган вакыт ккадәр озайтып, бу хокук тулы күләмдә торгызыла.

Башка очракта лицензия вакыты озайтылмый.

19 статья. Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктатып тору һәм чикләү өчен сәбәпләр

/I/ Җир асты байлыкларыннан нәтиҗәле файдалану, аларны һәм табигый тирә-як мохитне саклау таләпләрен бозган очракларда җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы чикләнергә мөмкин.

/2/ Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы түбәндәге очракларда туктатып торылырга мөмкин:

1/ җир асты байлыкларыннан нәтиҗәле файдалану, аларны һәм табигый тирәлекне саклау таләпләрен даими рәвештә бозган өчен;

2/ тау предприятиесен имин эксплуатацияләүнең кагыйдәләрен һәм нормаларын бозган өчен;

3/ җир асты байлыклары өчен кертелә торган түләүнең лицензиядә күрсәтелгән күләме, рәвеше һәм тәртибе шартларын үтәмәгән өчен.

Җир асты байлыкларыннан файдаланучы ачыкланган закон бозуларны бетергәнче, җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы чикләнә яисә туктатылып тора.

20 статья. Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын чикләү һәм туктатып тору тәртибе

/1/ Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган законнарда күрсәтелгән вәкаләтләре нигезендә лицензия бирүче органнар һәм тау предприятиеләренең эшчәнлеген тикшерүче һәм күзәтүче органнар чикләргә яисә туктатып торырга мөмкиннәр.

## III бүлек. Җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләүләр

21 статья. Җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләү

/1/ Әлеге Законда каралган очраклардан гайре, җир асты байлыкларыннан файдалану түләүле була.

/2/ Җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләү файдалы казылмаларның запасларын нәтиҗәле һәм тулы куллануга кызыктыру, шулай ук файдалы казылмаларның запасларын булдыру, җир асты байлыкларын һәм тирә-як мохитне саклау максатларында билгеләнә.

/3/ Җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләү, милек, оешу-хокук рәвешләренә, кемгә буйсынуларына карамастан, җир асты байлыкларын хуҗалык эшчәнлегенә җәлеп итүче физик һәм юридик затлардан алына.

/4/ Җир асты байлыклары өчен түләү тәртибе, ташламалар бирү һәм түләүләрне кичектерүләр тәртибе Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә һәм Татарстан Республикасы Югары Советы тарафыннан раслана, ә республика бюджетына, җирле бюджетларга һәм тиешле финанс фондларына кертелүче түләүләрнең күләмнәрен һәм өлешләрен Татарстан Республикасы Югары Советы Татарстан Республикасының дәүләт бюджетын караганда билгели.

22 статья. Түләүләрнең төрләре

/1/ Җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләүләр ставкалар рәвешендә билгеләнә. Түләүләрнең системасы түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1/ җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы һәм лицензия алган өчен түләү;

2/ чыгарылган файдалы казылмалар өчен түләү;

3/ файдалы казылмалар чыгару белән бәйле булмаган җир асты мәйданнарын кулланган өчен түләү;

4/ минераль байлыкларның запасларын яңадан торгызу һәм файдалы казылмалар чыгаруның нәтиҗәлелеген күтәрү өчен түләү.

/2/ Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы өчен түләүләр лицензияләрнең гамәли вакыты дәвамында бер генә тапкыр түләнә торган взнослар /бонуслар/ һәм шуннан соң даими түләнә торган түләүләр /роялтилар/ рәвешендә алына.

/3/ Башка төрле түләүләр дә алынырга мөмкин, шул исәптән җир өчен, геологик мәгълүматлар өчен, җир асты байлыкларына һәм тирә-як мохиткә китерелгән зыянны каплау өчен, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган законнарда каралган штрафлар, салымнар һәм җыемнар да алына.

/4/ Җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләүләр тәртибе әлеге Законның 2I статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә. Түләүләр түбәндәгечә кертелергә мөмкин:

I/ акчалата түләүләр;

2/ чыгарылган минераль чималның яисә кулланучы җитештергән башка продукциянең бер өлеше;

3/ эшләрне башкару яисә хезмәт күрсәтү;

4/ казылма байлыкларны эшкәртү һәм үзләштерү предприятиесенең устав фондына үз өлешен кертү рәвешендә республика яисә районнар /шәһәр районнарыннан гайре/ бюджетына түләүләр.

/5/ Түләүләрне кертү рәвеше җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы турында лицензиядә билгеләнә.

/6/ Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы өчен түләү сыйфатында Татарстан Республикасы законнары нигезендә Татарстан Республикасы Хөкүмәте карамагында булган радиоактив материалларны

һәм башка продуктларны таләп итү һәм кабул итү тыела.

23 статья. Җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен һәм лицензия биргән өчен түләү

/1/ Җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләүләр лицензияләр әзерләгән һәм биргән өчен җыемнардан һәм җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләүләрдән гайбарәт.

/2/ Лицензияләр биргән өчен җыем лицензия бирүче органнар тарафыннан алына. Җыемның күләме җир асты байлыкларыннан файдалану буенча бирелгән гаризаларны тикшерүгә киткән чыгымнарга, лицензия бирү белән бәйле оештыру һәм гамәлләр чыгымнарына карап билгеләнә һәм акчалата түләүләр рәвешендә башкарыла.

/3/ Эзләнүләр һәм разведка эшләрен уздыру хокукы өчен түләүләрнең күләме икътисади-географик шартларга, җир асты байлыкларының мәйданнары зурлыгына, казылма байлыкларның тирәнә, эшнең дәвамлылыгына, территориянең геологик яктан өйрәнелүенә һәм хәвеф-хәтәрлек дәрәҗәсенә карап билгеләнә.

/4/ Казылма байлыкларны чыгару хокукы өчен түләү казылма байлыкларның төрен, әлеге запасларның күләмен һәм сыйфатын, чыганакларны үзләштерүнең һәм эшкәртүнең табигый-географик, тау-техник һәм икътисадый шартларын, хәвеф-хәтәрлек дәрәҗәсен исәпкә алып билгеләнә.

/5/ Казылма байлыкларны чыгару белән бәйле булмаган максатларда, шул исәптән җир асты җайланмаларын төзү һәм алардан файдаланганда җир асты байлыкларын куллану хокукы өчен түләү җир асты мәйданнарына һәм әлеге байлыклардан файдаланганда экологик хәвеф-хәтәр дәрәҗәсенә карап билгеләнә.

24 статья. Чыгарылган казылма байлыклар өчен һәм казылма байлыклар чыгару белән бәйләнмәгән җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләү

/I/ Чыгарылган казылма байлыклар өчен түләү күләме гамәлләштерелгән минераль чимал хакыннан бер өлеш буларак билгеләнә, ә казылма байлыклар чыгару белән бәйләнмәгән җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләү башкарылган эшләр хакыннан яисә казылма байлыклар чыгару белән бәйләнмәгән җир асты байлыкларыннан файдаланганда күрсәтелгән хезмәтләрнең хакыннан бер өлеш буларак билгеләнә.

25 статья. Минераль ресурслар запасларын торгызган һәм казылма байлыкларны чыгаруның нәтиҗәлелеген арттырган өчен түләү

/I/ Минераль ресурслар запасларын торгызган өчен түләүләр түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

I/ минераль ресурслар запасларын торгызу өчен кертемнәр;

2/ казылма байлыкларны чыгаруның нәтиҗәлелеген арттырган өчен кертемнәр.

/2/ Кертемнәр күләме, әлеге статьяга яраклаштырып, гамәлләштерелгән минераль ресурслар хакының зурлыгына процент чагыштырмасы рәвешендә билгеләнә.

/3/ Минераль ресурслар запасларын торгызган өчен кертемнәр,шулай ук казылма байлыкларны чыгаруның нәтиҗәлелеген арттырган өчен кертемнәр продукциянең үз кыйммәтенә кертеп исәпләнелә.

/4/ Түләүләрне билгеләү, җыеп алу һәм акчаларны тоту тәртибе, әлеге статьяга яраклаштырып, Татарстанның бюджеттан тыш фондлары турында законнар нигезендә Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.

26 статья. Чыгарылган казылма байлыклар өчен түләүләргә ташламалар

/I/ Чыгарылган казылма байлыклар өчен түләүләргә ташламалар түбәндәгеләргә тәкъдим ителергә мөмкин:

I/ Татарстан Республикасы Югары Советы ризалыгы белән Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан һәр ел саен билгеләнә торган исемлектәге сирәк очраучы казылма байлыкларны чыгару белән бәйле җир асты байлыкларыннан файдаланучыларга;

2/ чыганаклар эшкәртүнең объектив шартлар аркасында (запаслар азаю очрагында,шулай ук нефть чыганаклары катламнарында 85%ы

су булган очракларда һәм нефтьнең артык үзле чыганаклары, түбән коллектор сыйфатлы катламнары булган очракларда, түбән икътисадый нәтиҗәләргә китерүче казылма байлыклар чыгаруны гамәлгә ашыручыларга.

(2) Чыгарылган казылма байлыклар өчен түләүләрнең ставкасына ташламалар күләмен ачыклау тәртибен Татарстан Республикасы Хөкүмәте билгели.

27 статья. Җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләүләргә ташламалар

/I/ Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы турында лицензияләр биргән өчен түләүләрдән төбәктә геологик-геофизик эшләр, геологик рәсемгә төшерүләр, җир тетрәүләрне күзаллау буенча башка геологик эшләр, инженер-геологик эзләнүләр, палеонтологик, геоэкологик күзәтүләр уздыручылар, җир асты суларының режимын тикшерүчеләр, казылма байлыклар чыганакларын эзләүчеләр һәм аларны эшкәртүгә әзерләүчеләр, шулай ук җир асты байлыкларының бөтенлегенә зыян китерми генә дәүләт бюджеты исәбеннән башка эшләр алып баручылар азат ителәләр.

/2/ Чыгарылган казылма байлыклар өчен түләүдән түбәндәгеләр азат ителә:

I/-нефть чыгаруны яңа, экологик имин һәм алдынгы ысуллар белән алып баручы җир асты байлыклары урнашкан мәйданнардан файдаланучылар;

- нефть һәм газ компонентларын чыгару лицензиядә күрсәтелмәгән булып та, нефть һәм газ чыгарган вакытта ияреп чыгучы компонентларны гамәлгә ашыручылар;

- яңа технологияләр керткән вакытта нефть һәм газны югалтуларны киметү исәбенә алынган продукцияләре булган җир асты байлыкларыннан файдаланучылар;

2/ дәүләт,республика һәм җирле бюджетлар исәбеннән финансланучы яисә үзләрендә дәвалау өчен казылма байлыклар кулланучы, кәсби берлекләр /профсоюзлар/ исәбеннән финансланучы дәвалау учреждениеләре;

3/ милкендәге җир биләмәләрендә яисә арендага алынган җирләрдә үз ихтыяҗлары өчен су белән тәэмин итү башкарылган, эчәр сулар белән тәэмин итү максатларында җир асты суларыннан файдалану;

4/ билгеләнгән тәртиптә рөхсәте булган, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен төче сулардан файдаланучылар;

5/ әлеге Закон нигезендә үзләренә караган яисә арендага алынган мәйданнарда үз ихтыяҗлары өчен киң таралган файдалы казылмаларны чыгаручы җир хуҗалары;

6/ әлеге Законда күрсәтелгән махсус саклаучы геологик объектларны төзү өчен җир кишәрлекләре алучылар.

### IУ бүлек. Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, минераль чимал ресурсларын һәм запасларын исәпкә алу

### 28 статья. Җир асты байлыкларын геологик өйрәнүнең максаты һәм бурычлары

/1/ Татарстан Республикасы җир асты байлыкларының геологик төзелешен өйрәнүнең максаты - җир асты байлыкларыннан нәтиҗәле файдалануның һәм аларны саклауның, шулай ук аларны киләчәктә дә өйрәнүнең озакка сузылган һәм агымдагы республика программаларын эшләү өчен минераль чимал ресурсларының төзелеше, үзенчәлекләре,

егәре һәм казылма байлыкларның запаслары турында мәгълүмат алу.

/2/ Җир асты байлыкларын геологик өйрәнүгә түбәндәгеләр керә:

1/ Татарстан Республикасы җир асты байлыкларының геологик төзелеше закончалыклары хакында мәгълүматлар алу һәм аларда казылма байлыкларны урнаштыру;

2/ минераль чимал чыганакларын ачу өчен яраклы җир асты байлыклары мәйданнарын ачыклау;

3/ казылма байлыкларны эшкәртүнең һәм чималны куллануның нәтиҗәле ысулын ачыклау өчен табылган чыганаклардагы казылма байлыкларның төрен, күләмен һәм технологик үзенчәлекләрен билгеләү;

4/ казылма байлыкларны чыгару белән бәйләнмәгән максатларда җир асты байлыклары мәйданнарын ачыклау;

5/ геологик гамәлләрнең һәм күренешләрнең - җир кабыгы хәрәкәтләренең, җир тетрәүләрнең, карст күренешләренең,таудан агымнар шуышу күренешләренең һ.б.ларның хуҗалык эшчәнлегенә һәм җир асты байлыкларыннан файдалануга тәэсирен исәпкә алу өчен алар хакында мәгълүмат алу;

6/ җир асты байлыкларыннан файдаланганда аны куллану максатларында геоэкосистеманың /геологик харитага төшерүнең/ халәте турында мәгълүмат җыю.

29 статья. Җир асты байлыкларын геологик өйрәнүнең тәртибе

/1/ Республика күләмендәге агымдагы яисә озак вакытларга исәпләнелгән программалар нигезендә, шулай ук кызыксынучы оешмалар һәм физик затлар заказы буенча, әлеге Законда күрсәтелгән тәртипләрдә республика җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, минераль чимал егәрен билгеләү, файдалы казылмаларның чыганакларын эзләү эшләре алып барыла.

/2/ Геологик хариталаудан гайре геологик разведка эшләрен башкару, шулай ук җир асты байлыкларын эшкәртү өчен алардан файдалану һәм казылма байлыкларны чыгару белән бәйләнмәгән эшләрне башкару табигатьне саклауның дәүләт органнары белән килешенелә.

/3/ Татарстан Республикасы территориясендә үткәрелүче геологик разведка барышының бөтен баскычларындагы эшләр, милек рәвешләренә һәм башкарма оешмаларның кайсы ведомствога буйсынуларына карамастан, Татарстанның республика геологик фондында теркалу узарга тиешләр. Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү буенча эшләрне дәүләт теркәвеннән башка уздыру тыела.

<u>30 статья.</u> Җир асты байлыкларын геологик өйрәнүгә төп таләпләр

/I/ Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү вакытында түбәндәгеләр үтәлергә тиеш:

I/ җир асты байлыкларын өйрәнүнең комплекслылыгы һәм хаклыгы, моңа казылма байлыклар чыганакларын эшкәртүнең тау технологиясе, гидрогеологик һәм җир асты байлыкларын эшкәртү һәм җир асты байлыкларын чыгару белән бәйләнмәгән җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләү дә керә;

2/ төп казылма байлыкларның һәм аңа ияреп чыгучыларның һәм алардагы компонентларның запаслары күләмен һәм сыйфатын билгеләүнең хаклыгы;

3/ алга таба җир асты байлыкларын өйрәнгәндә, казылма байлыкларның чыганакларын эзләгәндә һәм эшкәрткәндә, шулай ук казылма байлыкларны чыгару белән бәйле булмаган максатларда җир асты байлыкларыннан файдаланганда кулланыла торган геологик һәм башкарма техник документациянең, тау токымнары һәм рудаларның, кернның

үрнәкләре, файдалы казылмаларның сынауга алынган дубликатлары сакланышы.

31 статья. Җир асты байлыклары хакында геологик мәгълүматка хокуклар

/1/ Геологик мәгълүматка милекчелек хокукы Татарстан Республикасы законнары тарафыннан саклана. Җир асты байлыкларының геологик төзелеше, ресурслары һәм башка үзенчәлекләре турындагы мәгълүмат геологик эзләнү эшләрен финанслаучы субъектларның милке була.

/2/ Дәүләт чыганаклары исәбенә алынган геологик мәгълүмат Татарстан Республикасының Геологик мәгълүмат(лар) фондына ул билгеләгән тәртиптә кертелә. Күрсәтелгән мәгълүматны куллану тәртибе һәм шартлары Татарстан Республикасы законнарына нигезләнеп билгеләнә.

/3/ Үз хисапларына җир асты байлыклары хакында геологик һәм башка мәгълүмат алган оешмалар, предприятиеләр һәм гражданнар әлеге мәгълүматны яисә аның турында белешмәләрне Татарстан Республикасының Геологик мәгълүмат(лар) фондына кертәләр һәм шартнамә нигезендә аның куллану шартларын билгелиләр. Урындагы затлар мәгълүматны җыйган, саклаган, тапшырган һәм башкача файдаланган очракта,шартнамә нигезендә аның сер итеп сакланышын тәэмин итә.

/4/ Җир асты байлыклары һәм аның үзенчәлекләре турындагы барлык геологик мәгълүмат шартнамә нигезендә мәгълүмат милекчеләре тарафыннан тапшырылырга, алмаштырылырга мөмкин.

32 статья. Казылма байлыкларның чыганакларын беренче ачучылар

/1/ Сәнәгатьтә әһәмияте булган чыганаклар яисә аның билгеләрен ачучы, шулай ук электән билгеле булган чыганакларда казылма байлыкларның өстәмә запасларын яки әлеге чыганакның сәнәгатьтә

әһәмиятен арттыра торган яңа минераль чимал табучылар, яисә яңа чыганаклар ачу мөмкинлеген теоретик яктан дәлилләүчеләр беренче ачучылар дип танылалар. Алар Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан вәкаләтле органда үз ачышларын теркәргә хаклы.

/2/ Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан вәкаләтле әлеге орган ачышның әһәмиятен расласа, беренче ачыш ясаучылар бүләккә хаклылар.

/3/ Бүләкләүнең күләме һәм аны түләү тәртибе Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.

33 статья. Казылма байлыклар чыганакларындагы минераль чималның кондицияләре

/I/ Чыганакларның сәнәгатьтәге әһәмиятен билгеләү һәм алардагы запасларны исәпләү өчен, киләчәктә аларның һәр чыганак буенча комплекслы кулланылышын ачыклау өчен минераль чималның кондицияләре билгеләнә, бу кондицияләр казылма байлыкларның сыйфатына һәм күләменә, чыганакларны эшкәртүнең тау геологиясе һәм башка шартларына икътисади нигезләнгән таләпләрдән гыйбарәт.

/2/Кондицияләр Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә раслланалар.

/3/ Киң таралган казылма байлыкларның сыйфатына таләпләр мәгълүм тәртиптә раслана торган республика һәм тармак стандартлары тарафыннан билгеләнә.

34 статья. Казылма байлыкларның запасларын экспертизалау һәм раслау

/I/ Җентекләп өйрәнелгән чыганаклардагы казылма байлыкларның запасларына, шулай ук чыганакларны эшкәртү барышында өйрәнеп бетерелгән казылма байлыклар запасына экспертиза үткәрелергә тиеш, бу вакытта казылма байлыклардагы өйрәнелгән запасларның һәм аларның үзенчәлекләренең хаклыгы билгеләнә.

/2/ Казылма байлыклар чыганакларын эшкәртү белән бәйләнмәгән җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен яраклы җир асты мәйданнары турындагы геологик мәгълүмат дәүләт экспертизасы узарга тиеш. Мондый җир асты мәйданнарын кулланылышка тапшыру дәүләт геологик мәгълүматы уздырылганнан соң гына рөхсәт ителә.

/3/ Экспертиза үткәрү һәм каты казылма байлыкларның, җир асты суларының запасларын раслау тәртибе Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә, ә нефть һәм газ буенча - Татарстан Республикасы законнары нигезендә.

/4/ Әгәр экспертизага тәкъдим ителә торган геологик материаллар казылма байлыклар запасының күләмен һәм сыйфатын, аларның хуҗалыктагы әһәмиятен, тау-техник, гидрогеологик, экологик һәм аларны чыгаруның башка шартларын объектив бәяләүгә нигез була алса, чыганакларны геологик өйрәнүнең теләсә кайсы стадиясендә дәүләт экспертизасы үткәрелергә мөмкин. Казылма байлыкларны чыгару өчен җир асты байлыклары мәйданнарын кулланылышка бирү аларның запасларына дәүләт экспертизасы уздырылганнан соң гына рөхсәт ителә.

/5/ Казылма байлыкларны бер үк вакытта геологик өйрәнү һәм чыгару өчен җир асты байлыклары мәйданнарын кулланылышка биргәндә, җир асты байлыкларын кулланучылар, Татарстан Республикасы Хөкүмәте рөхсәте белән һәм лицензия нигезендә казылма байлыклар запасына дәүләт экспертизасы уздырылганчы ук, аларны чыгаруга керешә алалар. Җир асты байлыкларыннан файдалану һәм түләү шартларын ачыклап, материалларны дәүләт экспертизасына чираттагы тапшыру вакытлары җир асты байлыкларыннан файдалану хокукына лицензия шартларында килешенә.

/6/ Дәүләт экспертизасы бәяләмәсе казылма байлыкларның өйрәнелгән запасларын дәүләт исәбенә куюга нигез булып тора.

/7/ Казылма байлыклар запасына, кулланылышка тапшырылучы җир асты байлыклары мәйданнары турында геологик мәгълүматка дәүләт экспертизасы Татарстан Республикасы Хөкүмәте вәкаләт биргән орган тарафыннан үткәрелә.

35 статья. Татарстан Республикасы казылма байлыкларының запасларын дәүләт исәбенә алу, аларның чыгу һәм бүленү урыннарының кадастры

/I/ Казылма байлыкларның чыганакларындагы , шулай ук бүленү урыннарындагы запаслары казылма байлыклар чыганагының һәм бүленүенең дәүләт кадастры рәвешендә дәүләт исәбенә алынырга тиеш.

/2/ Казылма байлыклар чыганакларының һәм бүленү урыннарының дәүләт кадастры Татарстан Республикасы территориясендәге барлык чыганакларны һәм бүленү урыннарын үз эченә ала.

/3/ Дәүләт кадастрында һәр чыганак буенча аның геологик төзелеше, төп һәм аның янәшәсендә ятучы казылма байлыклар запасларының, алардагы компонентларның сыйфаты һәм күләме хакында, тау-техник, гидрогеологик һәм чыганакларны эшкәртүнең башка шартлары, аның геологик-икътисадый һәм экологик бәяләмәсе хакында мәгълүматлар булырга тиеш.

/4/ Казылма байлыкларның һәр беленү урыны буенча аларның геологик төзелешен һәм ресурсларын кузаллауны бәяләү турында мәгълүматлар булырга тиеш.

/5/ Казылма байлыклар чыганакларының һәм беленү урыннарының геологик кадастры Татарстан Республикасының Геологик мәгълүматлар фонды тарафыннан башкарыла.

36 статья. Татарстан Республикасының казылма байлыклары запасларының дәүләт нисбәте /балансы/

/I/ Сәнәгать әһәмиятенә ия казылма байлыклар запасларының дәүләт нисәбәте чыганаклардагы казылма байлыклар запасының күләме,сыйфаты һәм өйрәнелеш дәрәҗәсе хакында, аларның урнашуы, сәнәгатьтә үзләштерелеше, чыгарылышы, югалтулар дәрәҗәсе һәм сәнәгатьнең өйрәнелгән казылма байлыклар запаслары белән тәэмин ителеше турындагы мәгълүматларны үз эченә алырга тиеш.

/2/ Запасларның дәүләт нисбәте казылма байлыклар чыганаклары һәм техноген ресурслар өчен аерым төзелә.

/3/ Казылма байлыклар запасларының дәүләт нисбәте минераль чимал эзләүче һәм аны чыгаручы предприятиеләрнең дәүләт статистик хисабы нигезендә төзелә. Мәгълүмат бирү тәртибе һәм аның күләме Татарстан Республикасы законнары тарафыннан билгеләнә.

/4/ Казылма байлыклар запасының дәүләт республика нисбәте Татарстан Республикасының Геологик мәгълүматлар фонды тарафыннан алып барыла.

37 статья. Казылма байлыклар чыганакларының резервлары

/I/ Казылма байлыкларның ачылган, бәяләнгән табигый һәм техноген чыганаклары республиканың минераль чимал базасы резервларын тәшкил итә.

/2/ Казылма байлыклар чыганакларының резервлары түбәндәгеләргә бүленә:

I/ чыганакларның республика резервы Татарстан Республикасы Хөкүмәте вәкаләтләгән орган тарафыннан оештырыла;

2/ районнар/шәһәрләр/ резервы Татарстан Республикасының Геологик мәгълүматлар фондына кертелмәгән казылма байлыклар чыганакларыннан гыйбарәт.

38 статья. Казылма байлыклар запасларын гамәлдән чыгару

/I/ Чыгарылган казылма байлыклар, шулай ук сәнәгатьтә әһәмиятен югалткан, чыгару барышында югалган, яңадан үткәрелгән геологик эзләнүләр барышында яисә чыганакларны эшкәрткәндә барлыгы беленмәгән казылма байлыклар аларны чыгаручы предприятиеләр исәбеннән төшереп калдырылырга тиеш, бу вакытта Татарстан Республикасы законнарында күрсәтелгән тәртиптә казылма байлыклар запасларының дәүләт нисбәтенә тиешле үзгәрешләр кертелә.

/2/ Казылма байлыкларның һәм җир асты суларының запаслары предприятиеләр исәбеннән Татарстан Республикасы законнары билгеләгән тәртиптә Казылма байлыкларның запаслары буенча Татарстан Республикасы комиссиясе һәм Татарстан Республикасының Геологик мәгълүматлар фонды тарафыннан төшереп калдырыла.

## У бүлек. Казылма байлыклар чыганакларын эшкәртү өчен һәм казылма байлыклар чыгару белән бәйләнмәгән максатларда җир астын куллану

39 статья. Җир асты байлыкларыннан файдалану тәртибе

/I/ Казылма байлыкларны чыгару белән бәйле булмаган җир асты байлыкларын файдалану һәм чыганакларны эшкәртү предприятиеләрнең проектларында билгеләнгән тәртиптә расланган файдалы казылмаларның чыганакларын эшкәртү проектлары һәм схемалары нигезендә, шулай ук техник эксплуатацияләү, хезмәтне саклау, куркынычсызлык техникасы һәм тирә-як мохитне саклау кагыйдәләренә таянып һәм җир асты байлыкларыннан файдалану хокукына лицензиядә билгеләнгән шартларда гамәлгә ашырыла.

/2/ Җитештерүнең агулы калдыкларын күмү һәм агып төшкән суларны агызу каралган проектлар тирә-як мохитнең халәтен һәм

һәм сәнәгатьтә үзләштерүнең куркынычсызлыгын тикшерә торган дәүләт органнарында экспертиза үтәргә , шулай ук калдыклар күмелгән зонада яшәүче халык мәнфәгатьләрен яктыртучы халык депутатларының җирле Советлары белән килешенгән булырга тиеш.

<u>40 статья.</u> Җир асты байлыкларыннан файдаланганда үтәлергә тиешле төп таләпләр

/I/ Казылма байлыкларның чыганакларын эшкәрткәндә һәм минераль чималны яңадан эшкәрткәндә, файдалы казылмаларны чыгару белән бәйләнмәгән җир асты байлыкларыннан файдаланганда түбәндәгеләр тәэмин ителергә тиеш:

I/ төп һәм аның янәшәсендә ятучы казылма байлыкларны чыгаруның аеруча нәтиҗәле һәм экологик яктан зарарсыз, чыганакларны бозмый, нормадан тыш югалтуларга китерми торган алымнарын куллану, казылма байлыклар запасын сайлап эшкәртү;

2/ җир асты эшләрен башкару нәтиҗәсендә казылма байлыклар эшкәртелә торган һәм алар янәшәсендәге чыганакларны бозуны булдырмау; шулай ук җир астында вакытлыча эшкәртүдән туктатылган файдалы казылмаларның запасын һәм алда кулланылырга тиешле җир асты казылмаларының эшкәртелгән аралыгын саклау;

3/ бер уңайдан чыгарыла һәм вакытлыча кулланылмый торган казылма байлыкларны саклау һәм исәпкә алу;

4/ икътисади табышлы технология булган очракта һәм җитештерү планнары нигезендә минераль чималны, андагы кыйммәтле компонентларны аерып, комплекслы яңадан эшкәртү;

5/ еске катламнарны нәтиҗәле файдалану, шулай ук аларны дерес урнаштыру;

6/ минераль чималны беренчел эшкәрткәндә, әлеге чималның компонентларын максималь һәм комплекслы алуны тәэмин итүче геологик-сәнәгать типларына карата яңадан эшкәртүнең кабул ител-

гән технологик схемаларын һәм экологик нормативларны үтәү зарури;

7/ запасларның халәте һәм хәрәкәте, чималны югалту һәм ярлыландыру мәсьәләләре буенча исәп һәм дәүләт статистика исәбе,шулай ук җир асты байлыкларының эшкәртелгән аралыгының чыганакларын үзләштерүнең һәм куллануның комплекслылыгын һәм җир асты массивында шуңа бәйле килеп чыга торган киеренкелекне исәпкә алу;

8/ эшчеләрнең һәм халыкның тормышы, сәламәтлеге өчен куркынычсызлык, экологик куркынычсызлык тәэмин итү, җир асты байлыкларын, табигый тирәлекнең башка объектларын, биналарны һәм корылмаларны саклау;

9/ агым суларны, зарарлы матдәләрне, җитештерү калдыкларын һәм башка матдәләрне һәм материалларны зарарсызландыру яисә аларны катгый билгеләнгән чикләрдә тотып калу һәм аларның җир асты байлыкларын эшкәртү урынына, җир өстенә һәм су объектларына үтеп керүләренә киртә кую, шулай ук табигый тирәлекне саклауны тәэмин итүче башка чаралар куллану.

**4I статья.** Казылма байлыкларны чыгару буенча предприятиеләрне һәм казылма байлыкларны чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын ябу һәм вакытлыча эштән туктату

/I/ Казылма байлыклар запаслары эшкәртелеп беткәч яисә лицензиянең гамәли вакыты чыккач, шулай ук техник-икътисади, экологик һәм башка сәбәпләр аркасында чыганакларны яисә аларның нинди дә булса өлешен алга таба эшкәртү мөмкин булмаса яисә муафыйк саналмаса, казылма байлыклар чыгаручы, чыганаклар эшкәртүче предприятие яисә әлеге предприятиенең аерым өлеше /аерым скважиналарга кадәр/ ябыла яисә вакытлыча эштән туктатыла.

/2/ Казылма байлыкларны чыгаручы предприятиеләрне тулысынча яисә өлешчә япканда яки вакытлыча эштән туктатканда җир астында эшләү урыннары һәм бораулау скважиналары халыкның .иминлеген, тирә-як мохитне, биналарны һәм корылмаларны саклауны тәэмин итүче халәткә китерелергә тиеш, ә вакытлыча туктатканда, туктатылган барлык вакытка предприятиеләрнең, эшләү урыннарының һәм скважиналарның сакланышы да тулысынча тәэмин ителергә тиеш. Казылма байлыкларны чыгару буенча предприятиеләр ябылганда, җир астында эшләү урыннарын һәм бораулау скважиналарын халык хуҗалыгының башка тармакларында куллану мөмкинлекләре турындагы мәсьәлә хәл ителгән булырга тиеш.

/3/ Казылма байлыкларны чыгару буенча предприятие яисә аның аерым бер өлеше ябылганда һәм вакытлыча эштән туктатылганда геологик һәм маркшейдер. — —> документацияләр җир асты эшләре тәмамлану вакытына тутырыла һәм билгеләнгән тәртиптә саклауга тапшырыла.

/4/ Лицензия биргән органнар һәм Татарстан Хөкүмәте шуңа вәкаләт биргән дәүләт җир асты күзәтүе органы тарафыннан ябу яисә вакытлыча эштән туктату турында актка имза салынгач кына, казылма байлыклар чыгару буенча предприятиеләрне яисә казылма байлыклар чыгару белән бәйле булмаган җир асты корылмаларын ябу һәм вакытлыча эштән туктату тәгәлләнгән дип санала.

42 статья. Казылма байлыклар яткан мәйданнарны төзү шартлары

/1/ Торак пунктларын, сәнәгать комплексларын һәм башка хуҗалык объектларын проектлаштыру һәм төзү бары тик төзелеш булачак мәйдан астында казылма байлыкларның юклыгы турында мәгълүматлар алынгач кына рөхсәт ителә.

/2/ Казылма байлыклар яткан мәйданнарны төзү, шулай ук алар яткан урыннарда җир асты корылмаларын урнаштыру бары тик

казылма байлыклар чыгару мөмкинлеге тәэмин ителгән яисә төзелешнең икътисади муафыйклыгы исбатланган шартларда гына нәтиҗәле файдалануны һәм җир асты байлыкларын саклауны дәүләт тарафыннан тикшерүне гамәлгә ашыручы органнар, шулай ук җир астын күзәтү органнары тарафыннан рөхсәт ителә.

## УI бүлек. Җир астыннан файдалану белән бәйле эшләрнең куркынычсызлыгы

**43 статья.** Җир асты байлыкларыннан файдалану белән бәйле җир асты эшләрен алып баруда куркынычсызлыкны тәэмин итү

/I/ Казылма байлыклар чыгаручы предприятиеләргә төрле тирәнлектәге җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләү, җир асты байлыкларын геологик өйрәнүне уздыру әлеге предприятиеләрдә эшләүчеләрнең һәм әлеге эшләр тәэсире зонасындагы халыкның иминлеген тәэмин иткән һәм сәламәтлекләрен саклаган очракларда гына рөхсәт ителә.

/2/ Дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары, Татарстан Хөкүмәте тарафыннан вәкаләтлек бирелгән җир астыннан файдаланучылар һәм күзәтү органнары үз вәкаләтләре кысаларында законнар таләпләренең үтәлешен тәэмин итәргә, шулай ук җир астыннан файдалану белән бәйле эшләрне алып баруның куркынычсызлыгы буенча билгеләнгән тәртиптә расланган стандартларның (нормаларның, кагыйдәләрнең) үтәлешен таләп итәргә тиеш.

/3/ Җир астыннан файдалану белән бәйле эшләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен турыдан-туры җаваплылык предприятиеләрнең җитәкчеләренә йөкләнә, предприятиеләр лицензияләр нигезендә эшләр алып баралармы яисә шартнамә нигезендә эшкә җәлеп ителгәннәрме - барыбер.

/4/ Җир астыннан файдаланучылар, җитештерүнең куркыныч очракларын һәм хәлакәтләрне алдан күреп, аларны булдырмауны, шул исәптән ачык газ һәм нефть фонтаннарын ябуны тәэмин итәргә тиеш.

/5/ Җир асты байлыкларыннан файдалану белән бәйле эшләр алып баручы предприятиеләрнең җитәкчеләре, моңа вәкаләтле урындагы затлар, әлеге предприятие хезмәткәрләренең тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч янаганда, эшләрне кичекмәстән туктатырга һәм кешеләрне куркынычсыз урынга күчерүне тәэмин итәргә тиешләр.

/6/ Җир асты байлыкларын файдалану белән бәйле эшләр тәэсирендәге зонада урнашкан халыкның тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч янаганда, тиешле предприятиеләрнең җитәкчеләре бу турыда дәүләт идарәсенең тиешле органнарына, җирле администрациягә кичекмәстән хәбәр итәргә, шулай ук Татарстан Республикасының гадәттән тыш вәзгыятьләр турындагы законнарында каралган башка чараларны гамәлгә ашырырга тиеш.

/7 / Казылма байлыклар чыгаручы предприятиеләрдә һәләкәт булган очракта җирле администрация, шулай ук башка предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар, милек рәвешләренә һәм нинди ведомствога буйсынуларына карамастан, һәлакәтне туктату өчен транспорт, материаллар, җайланмалар, элемтә чаралары, медикаментлар бирергә һәм гадәттән тыш вәзгыятьләр турында Татарстан законнарында каралган башка төр ярдәм күрсәтергә тиеш.

44 статья. Эшләрне имин алып баруны тәэмин итүнең төп таләпләре

/I/ Җир асты байлыкларын файдалану белән бәйле эшләрне имин алып баруны тәэмин итүнең төп таләпләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

I/ эшкә махсус әзерлеге һәм квалификациясе булган затларны җәлеп итү;

2/ тау эшләре һәм бораулау эшләре белән мәшгуль затларны

шәхси һәм күмәк саклау̸н чаралары һәм шул исәптән махсус киемнәр белән тәэмин итү;

3/ куркынычсызлык кагыйдәләренә һәм санитар нормаларга туры килерлек машиналар, җайланмалар һәм материаллар куллану;

4/ шартлаткыч матдәләрдән һәм шартлату чараларыннан дөрес файдалану, аларны тиешле рәвештә исәпкә алу, саклау һәм куллану;

5/ кагыйдәләргә һәм нормаларга нигезләнеп, җитештерү барышының ышанычлылыгын тикшерү һәм хәвефле вәзгыятьләр килеп чыгуны күзаллау өчен җитәрлек итеп күзәтүләр комплексын уздыру;

6/ җир асты байлыкларын файдалану белән бәйле эшләр алып баручы предприятиеләрнең хезмәткәрләрен һәм әлеге эшләрнең йогынтысы булырлык зонада урнашкан халыкны гадәти шартларда һәм хәвефле вәзгыятьләр килеп чыкканда бу эшләрнең йогынтысыннан саклауны тәэмин итүче гамәлләр әзерләү һәм уздыру.

## VII бүлек. Җир асты байлыкларыннан нәтиҗәле файдалану һәм аларны саклау

### 45 статья. Җир асты байлыкларыннан нәтиҗәле файдалануның һәм аларны саклауның төп таләпләре

/I/ Җир асты байлыкларыннан нәтиҗәле файдалануның һәм аларны саклауның төп таләпләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

I/ җир асты байлыкларын файдалануга бирүнең законнарда билгеләнгән тәртибен саклау һәм җир асты байлыкларыннан рөхсәтсез файдалануны булдырмау;

2/ җир асты байлыкларыннан нәтиҗәле файдалану һәм аларны саклау өчен, Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган законнарга таянып, әлеге максатларга тотылучы акчаларны үз вакытында күчерү юлы белән матди нигез булдыру;

3/ җир асты байлыкларын геологик өйрәнүнең, аларны нәтиҗәле, комплекслы куллануның һәм саклауның бөтенлеген тәэмин итү;

4/ казылма байлыклар чыгару белән бәйле булмаган максатларда файдалануга тапшырылган җир асты мәйданнарының казылма байлык запасларын һәм үзенчәлекләрен дөрес бәяләүне тәэмин итүче геологик өйрәнүләрне алдан уздыру;

5/ казылма байлыклар запасына һәм казылма байлыклар чыгару белән бәйләнеше булмаган максатларда кулланылучы җир асты мәйданнарына дәүләт экспертизасы үткәрү һәм аларны дәүләт исәбенә алу;

6/ төп казылма байлыкларның һәм алар янәшәсендә ятучыларның, юл уңаенда очраган компонентларның запасларын мөмкин кадәр күбрәк чыгаруны тәэмин итү;

7/ казылма байлыклар чыганакларын эшкәрткәндә җир куеныннан чыгарылган һәм анда калган төп казылма байлыкларның, алар янәшәсендә ятучыларның һәм юл уңаенда очраган компонентларның запасларын төгәл исәпкә алу;

8/ казылма байлыклар чыганакларын су басудан, сугарудан, янгыннардан һәм казылма байлыкларның сыйфатын түбәнәйтүче, чыганакларның сәнәгатьтәге әһәмиятен киметүче яисә эшкәртүдә кыенлыклар тудыручы башка факторлардан саклау;

9/ җир астын файдалану белән бәйле эшләр башкарганда, бигрәк тә нефть, газ яисә башка матдәләрне һәм материалларны җир астында саклаганда, зарарлы матдәләрне һәм җитештерү калдыкларын күмгәндә, агым суларны агызганда җир астын пычранудан саклау;

10/ казылма байлыклар чыгаручы һәм казылма байлыклар чыгаруга бәйләнеше булмаган предприятиеләрне һәм җир асты корылмаларын ябу һәм вакытлыча эштән туктатуның билгеле тәртипләрен саклау;

II/ казылма байлыклар яткан мәйданнарда рөхсәтсез төзелешләр алып баруны кисәтү һәм әлеге мәйданнарны башка максатларда куллануның мәгълүм тәртипләрен үтәү;

I2/су җыю мәйданнарында һәм эчәргә яраклы сулар алу яисә сәнәгатьне су белән тәэмин итү өчен кулланылучы җир асты сулары булган урыннарда сәнәгать һәм көнкүреш калдыкларының тупланып ятуын булдырмау.

46 статья. Фәнни һәм мәдәни әһәмияткә аеруча лаек булган җир асты байлыкларын саклау

/I/ Фәнни яисә мәдәни әһәмияткә аеруча лаек булган сирәк очрый торган геологик ачыклыкларны, минералогик төзелмәләрне, палеонтологик объектларны һәм башка җир асты мәйданнарын билгеләнгән тәртиптә геологик тыюлыклар, заказниклар яисә табигать һәм мәдәният һәйкәлләре дип игълан итәргә мөмкин. Күрсәтелгән тыюлыкларның, заказникларның һәм һәйкәлләре сакланышын бозучы теләсә нинди эшчәнлек тыела.

/2/ Җир астыннан файдаланганда сирәк очрый торган геологик һәм минералогик тезелмәләр, метеоритлар, палеонтологик, археологик һәм фән, мәдәният өчен әһәмияте булган башка объектлар килеп чыкса, җир астын файдаланучылар тиешле мәйданнардагы эшләрен туктатырга һәм бу турыда лицензия бирүче органнарга хәбәр итәргә тиеш.

47 статья. Җир астыннан нәтиҗәле файдалануны дәүләт тарафыннан тикшерү

/I/ Җир астыннан нәтиҗәле файдалануны һәм аны саклауны дәүләт тарафыннан тикшерүнең максатлары кулланучыларның җир астыннан файдаланудагы мәгълүм тәртипләрне, законнарны, геологик өйрәнүләр, җир астыннан файдалану һәм аны саклау өлкәсендә раслан-

ган стандартларны /нормаларны, кагыйдәләрне/, дәүләт хисабына алу һәм хисап тоту кагыйдәләрен үтәүләрен тәэмин итүдән гыйбарәт.

/2/ Җир астын нәтиҗәле файдалануны һәм аны саклауны дәүләт тарафыннан тикшерүне Татарстан Хөкүмәте моңа вәкаләт биргән органнар, дәүләт күзәтүенең һәм тикшерүенең башка органнары белән берлектә, гамәлгә ашыра.

/3/ Җир астыннан нәтиҗәле файдалануны һәм аны саклауны дәүләт тарафыннан тикшерү өлкәсендәге органнарның вәкаләтләре Татарстан Республикасы законнары тарафыннан билгеләнә.

/4/ Тикшерү органнары түбәндәгеләрне тикшерергә тиеш:

I/ җир астын өйрәнгәндә һәм аннан файдаланганда уздырылучы геологик эшләрнең расланган проектларга һәм лицензия шартларына туры килү-килмәвен;

2/геологик эзләнү циклының барлык стадияләрендә геологик тикшеренүләрнең нәтиҗәлелеген;

3/ казылма байлыкларны чыгаруның һәм аларны кулланының тулылыгын;

4/ казылма байлыклар чыганакларын су басулардан, янгыннардан һәм казылма байлыкларның сыйфатын, чыганакларның сәнәгатьтәге әһәмиятен киметүче һәм аларны эшкәртүдә кыенлыклар тудыручы башка факторлардан саклаучы чараларның нәтиҗәлелеген;

5/ җир астын пычратуны булдырмау системасының ышанычлылыгын, бигрәк тә җир астында нефть, газ, башка матдәләр һәм материаллар саклаганда, зарарлы матдәләрне, җитештерү калдыкларын күмгәндә, суларны агызганда.

/5/ Тикшерү органнары түбәндәге хокукларга ия:

I/ эш проектлары раслаган методикаларны бозып алып барыла торган җир асты байлыкларын геологик өйрәнү һәм аларны эшкәртү буенча эшләрне туктату;

2/ җир астында казылмалар барлыгы өйрәнелмәгән мәйданнарда нигезсез һәм башбаштакланып төзүне кисәтү һәм туктату;

3/ җир асты байлыкларыннан рөхсәтсез файдалануны һәм чыганакларны бозуга китерә торган эшләрне, шулай ук чыганакларны сайлап эшкәртүне туктату;

4/ Татарстан Республикасы законнары тарафыннан бирелгән башка вәкаләтләрне үтәү.

48 статья. Җир асты байлыкларыннан файдалану белән бәйләнгән эшләрне имин башкаруны дәүләт тарафыннан күзәтү

/I/ Җир асты байлыкларыннан файдалану белән бәйле эшләрне имин башкаруга дәүләт күзәтүенең бурычлары җир асты байлыкларыннан файдаланучыларның эшләрне имин башкару, халыкка, тирә-як мохиткә, биналарга һәм корылмаларга аларның зарарлы йогынтысын кисәтү һәм бетерү буенча законнарны, билгеләнгән тәртиптә расланган стандартларны (нормаларны, кагыйдәләрне) үтәүләрен тәэмин итүдән гыйбарәт.

/2/ Җир асты байлыкларыннан файдалану белән бәйле эшләрне имин башкаруга дәүләт күзәтүе (җир асты күзәтүе) Татарстан Республикасы Хөкүмәте вәкаләт биргән органнар тарафыннан гамәлгә ашырыла.

/3/ Дәүләт җир асты күзәтүе органнарының вәкаләтләре, хокуклары, вазыйфалары һәм аларның эш тәртибе Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган законнар тарафыннан билгеләнә.

/4/ Җир асты байлыкларыннан файдалану белән бәйле эшләрнең иминлеген дәүләт тарафыннан күзәтү органнары түбәндәгеләрне тикшерергә тиеш:

I/ эшләрне имин башкару буенча таләпләрнең һәм җир асты байлыкларын саклау буенча вазыйфаларның үтәлешен;

2/ геологик эзләнүләрнең һәм җир асты эшләренең куркынычсызлык шартларына туры килүен;

3/ казылма байлыклар чыганакларын эшкәрткәндә һәм казылма байлыклар чыгаруга бәйләнеше булмаган максатларда җир астыннан файдалануның мәгълүм тәртипләрен үтәүне.

/5/ Җир астын күзәтү органнары түбәндәге хокукларга ия:

I/ куркынычсызлык кагыйдәләрен һәм җир асты байлыкларын саклау нормаларын бозып эшләнә торган эшләрне туктату;

2/ законнарда билгеләнгән тәртиптә урындагы затларны һәм гражданнарны административ җаваплылыкка тарту;

3/ җир асты байлыклары турында законнардагы таләпләрне бозган очракларда җир асты байлыкларыннан рөхсәтсез файдалануны һәм казылма байлыклар яткан мәйданнарда рөхсәтсез төзүне туктату, шулай ук агым суларны җир астына агызуны, зарарлы матдәләрне һәм житештерү калдыкларын күмүне, матдәләрне һәм материалларны җир астында саклауны туктатып тору һәм туктату;

4/ Татарстан Республикасы законнары тарафыннан бирелә торган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

## УШ бүлек. Җир асты байлыкларыннан файдалану мәсьәләләре буенча бәхәсләрне хәл итү һәм җир асты байлыклары турында законнарны бозган өчен җаваплылык

49 статья. Бәхәсләрне хәл итү һәм шикаятьләрне карау тәртибе

/I/ Җир асты байлыкларына ия булу, алардан файдалану һәм аларны бүлү мәсьәләләре буенча бәхәсләрне, шулай ук әлеге мәсьәләләр буенча урындагы затларның, дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарының законга каршы гамәлләренә карата шикаятьләрне үз вәкаләтләре чикләрендә суд яисә Югары арбитраж суды карый һәм хәл итә.

50 статья. Җир асты байлыклары турында гамәлгә яраксыз килешүләр

/I/ Җир асты байлыкларына дәүләт милке хокукын бозып, шулай ук әлеге Законны бозып,турыдан-туры һәм яшерен рәвештә төзелгән килешүләр гамәлгә яраксыз дип таныла.

5I статья. Җир асты байлыклары турында законнарны бозган өчен җаваплылык

/I/ Җир асты байлыклары хакында законга каршы килә торган килешүләр төзүдә, шулай ук әлеге Законның башка положениеләрен бозуда гаепле затлар Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган законнар нигезендә административ җаваплылыкка һәм җинаять җаваплылыгына җәлеп ителәләр.

52 статья. Җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендәге хокук бозуларның төшенчәләре һәм төрләре

/I/ Җир асты байлыкларыннан файдалану турында Татарстан Республикасы законнарын хокукка каршы барып(аңлы рәвештә яки саксыз) бозу: әлеге Закон буенча хокук бозуларга керә.

/2/ Әлеге Закон нигезендә түбәндәгеләр хокук бозуларга керә:

I/ җир асты байлыкларыннан рөхсәтсез файдалану;

2/ җир асты байлыкларыннан файдалануның законнар тарафыннан билгеләнгән тәртибен бозу;

3/ җир асты байлыкларына дәүләт милке хокукын бозып, турыдан-туры яисә яшерен рәвештә гамәлгә яраксыз килешүләр әзерләү;

4/ җир асты байлыкларыннан файдалану турында законнарны бозып,җир асты байлыкларыннан файдалану белән бәйле килешүләр төзү;

5/ казылма байлыклар яткан мәйданнарны рөхсәтсез төзү;

6/ җир асты байлыкларыннан файдалану белән бәйле эшләрне имин башкару буенча, казылма байлыкларны һәм тирә-як мохитне саклау буенча билгеләнгән тәртиптә расланган стандартларның (нормаларның, кагыйдәләрнең) таләпләрен бозу, шул исәптән җир астын пычратуга китерүче һәм казылма байлыклар чыганакларын эксплуатацияләү өчен яраксыз хәләткә китерүче хокук бозулар;

7/ геологик һәм башка мәгълүматка милекчелек хокукларын яисә аның сер булып саклануын бозу;

8/ җир асты байлыкларыннан файдаланганда биналарның, корылмаларның, шулай ук аерым саклана торган территорияләрнең һәм табигый тирәлектәге объектларның саклануын тәэмин итмәү;

9/ җир асты суларының режимлы күзәтү скважиналарын, шулай ук маркшейдерлык һәм геодезик билгеләрне юк итү һәм сату;

10/ җир асты байлыкларыннан файдаланганда түләүләрне кертү тәртибен өзлекле рәвештә бозу;

11/ юкка чыгарылган яисә вакытлыча эштән туктатылган бораулау скважиналарын һәм җир астында эшләү урыннарын халыкның иминлеген тәэмин итүче халәткә китерү буенча таләпләрне, шулай ук туктатылган вакытка казылма байлыклар чыганакларының, эшләү урыннарының һәм бораулау скважиналарының саклануы буенча таләпләрне үтәмәү;

12/ җир кишәрлекләрен һәм башка табигый объектларны алга таба алардан файдаланырлык халәткә китермәү;

13/ чыганакларның бай кишәрекләрен сайлап эшкәртү нәтиҗәсендә казылма байлыкларның нисбәтле запасларын нигезсез югалту, казылма байлыкларны чыгарганда аларны нормадан тыш югалту һәм нормадан тыш ярлыландыру, казылма байлыклар чыганакларын

бозу һәм аларның запасларын нәтиҗәле файдалану буенча башка таләпләрне үтәмәү;

I4/ өйрәнеп бетерелгән казылма байлыклар запасларын яисә казылма байлыклар чыгару буенча предприятиеләр, шулай ук казылма байлыкларны чыгару белән бәйләнеше булмаган җир асты корылмалары төзү һәм эксплуатацияләү өчен шартларны дөрес бәяләмәүгә китерергә мөмкин булган яисә китерә торган геологик өйрәнүләр буенча җир астында эшләр алып бару кагыйдәләрен һәм таләпләрен бозу, алга таба җир асты байлыкларын геологик өйрәнүдә һәм чыганакларны эшкәртүдә кирәкле маркшейдер яки геологик документацияләрне, сынауга алынган казылма байлыкларның һәм кернүарның дубликатларын югалту.

53 статья. Җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендәге хокук бозулар өчен җаваплы затлар

/I/ Әлеге Закон буенча гражданнар һәм юридик затлар /предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар, милек, хуҗалык итү рәвешләренең нинди булуына карамастан/ җир астыннан файдаланучылар, шулай ук хезмәт вазыйфаларына җир асты байлыкларыннан файдалану буенча, тирә-як табигый мохитне саклау буенча билгеләнгән кагыйдәләрне һәм нормаларны үтәүне тәэмин итү кергән урындагы затлар җаваплылыкка тартылалар.

54 статья. Җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә хокук бозулар өчен җаваплылыкның күләме

/I/ Әлеге Законның 52 статьясында каралган хокук бозуларны кылган өчен административ тәртиптә салына торган штраф рәвешендәге җәза карала:

I/ гражданнарга - хокук бозулар кылынган мизгелгә Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган законнар тарафыннан билгеләнгән бер айлык минималь хезмәт хакыннан алып ун минималь хезмәт хакы күләменә кадәр;

2/ урындагы затларга - өч минималь хезмәт хакыннан алып егерме минималь хезмәт хакы күләменә кадәр;

3/ юридик затларга - үткән финанс елында алынган табышның 0,I процентыннан алып 3 процентка кадәр, әмма ул 1,0 млн. сумнан артмаска тиеш.

/2/ Салына торган штрафның күләме, хокук бозуның рәвешенә һәм төренә, хокук бозучының шәхесенә, аның гаебенең дәрәҗәсенә, мөлкәти халәтенә, шулай ук китерелгән зыянның зурлыгына карап, штраф салына торган орган тарафыннан билгеләнә.

/3/ Әгәр кылган хокук бозулар үзләренең рәвешләре буенча гамәлдәге законнар нигезендә җинаять җаваплылыгына җәлеп итүгә кермәсә, гражданнар һәм урындагы затлар әлеге статьяда каралган җаваплылыкка тартылалар.

/4/ Урындагы затка, гражданга яисә юридик затка карата административ җәза яки җинаять җәзасы куллану гаепләне китерелгән зыянны гамәлдәге законнар нигезендә һәм аларда билгеләнгән тәртиптә тулысынча кайтару вазыйфасыннан азат итми.

55 статья. Җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендәге административ хокук бозулар турында эшләр башкару тәртибе

/I/ Әлеге Законның 52 статьясында каралган хокук бозулар турында беркетмәләр җир асты байлыкларыннан нәтиҗәле файдалану һәм аны саклау буенча дәүләт тикшерүе, җир асты байлыкларыннан файдалану белән бәйле эшләрне имин башкару буенча дәүләт күзәтүе органнарының, табигый тирәлекнең торышын тикшерү буенча дәүләт органнарының шуңа вәкаләтле урындагы затлары тарафыннан төзелә.

/2/ Күрсәтелгән хокук бозулар турындагы эшләр шәхсән халык судьясы яисә Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды судьясы тарафыннан үз вәкаләтләре чикләрендә карала. Бу гамәлләр буенча

эшләр, шулай ук административ җәза бирү турында карарлар үтәлешенең тәртибе административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган законнар нигезендә билгеләнә.

/3/ Салынган штраф суммалары, Татарстан Республикасы Югары Советы белән килешеп, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмнәрдә тиешле бюджеттан тыш фондларның махсус хисапларына күчерелә. Җир асты байлыкларыннан файдалану турында законнарны бозган өчен салынган штраф суммаларының 3%ы җәмгыяви инфраструктура үсеше өчен һәм хокук саклау органнары һәм прокуратура хезмәткәрләренә матди булышлык күрсәтү өчен махсус бюджеттан тыш фондка җибәрелә, бу әлеге фонд турындагы положение нигезендә гамәлгә ашырыла.

<u>56 статья.</u> Зыянны кайтару

/I/ Предприятиеләр, оешмалар, учреждениеләр һәм гражданнар Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдәге законнарда билгеләнгән күләмнәрдә һәм тәртиптә җир асты байлыклары турында законнарны бозып китерелгән зыянны кайтарырга тиешләр. Зыянны кайтару белән бәйле чыгымнар тоткан предприятиеләрнең, оешмаларның һәм учреждениеләрнең гаепле урындагы затлары һәм башка хезмәткәрләре билгеләнгән тәртиптә матди җаваплы булалар.

/2/ Җир асты байлыкларыннан имин файдалануга, икътисадый нәтиҗәле файдалануга юл калдырмый торган, җир асты байлыкларыннан файдаланучыларның хокукларын чикли, казылма байлыклар чыганакларының һәм җир асты сулары чыганакларының табигый нәтиҗәлелеген, казылма байлыклар һәм җир асты сулары запасларының табигый сыйфатын киметә торган, казылма байлыклар яткан мәйданнарны төзү һәм биналарны һәм корылмаларны

саклауда, җир кишәрлекләрен һәм җир асты кишәрлекләрен су баскан-да һәм пычратканда гау-техник чараларны куллануның сыйфатын киметә, юридик затларның, гражданнарның, шулай ук дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарының /җирле үзидарәне һәм администрацияне кертеп/ башка гамәлләре нәтиҗәсендә казылма байлыкларны куллануның нәтиҗәлелеген ачыклаучы башка табигый рәвешләрне киметә торган зыяннар тулы күләмдә кайтарылырга тиеш /күздә тотылган файданы да кертеп/, ул әлеге Законда каралган тәртиптә җир асты байлыкларыннан файдалануга хокук бирелгән зыян күрүче җир асты байлыкларыннан файдаланучыларга кайтарыла.

3/ Зыян юридик затлар, дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары тарафыннан гамәлләре /гамсезьлекләре/ әлеге зыянны китереп чыгарган гражданнар тарафыннан билгеләнгән дәгъва-таләп тәртибендә кайтарыла.

/4/ Зыяннарны кайтару һәм аларның күләмнәрен билгеләү белән бәйле бәхәсләр әлеге Законның 49 статьясында каралган тәртиптә хәл ителә.

57 статья. Җир асты байлыклары милекчесенең җир асты байлыкларына йогынтысы нәтиҗәсендәге югалтуларын компенсацияләү

/I/ Җир асты байлыклары милекчесенең җир асты байлыкларын имин, икътисадый нәтиҗәле куллану мөмкинлегенә юл калдырмый торган, агымдагы елда һәм киләчәктә . җир кишәрлекләрен һәм җир астын төзү, су басу, пычрату, юридик затларның, гражданнарның, дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарының /җирле үзидарәне һәм администрацияне кертеп/ башка гамәлләре нәтиҗәсендә җир асты байлыкларыннан файдалану нәтиҗәсенең кимүенә сәбәп булган югалтулары тиешле бюджетларга һәм бюджеттан тыш фондларга компенсацияләнергә тиеш. Әлеге югалтуларга гамәли һәм көтелә торган

өстәмә чыгымнар[illegible] керә[illegible],шул исәптән геологик эзләнүләргә чыгымнар, чыгымнарның һәм керем чыганакларының Татарстан Республикасы законнары билгеләгән юнәлешләре буенча тиешле бюджетлар һәм максатчыл бюджеттан тыш фондлар керемнәренең югалтулары керә.

/2/ Югалтуларга компенсацияләр гамәлләре әлеге югалтуларны китереп чыгарган юридик затлар тарафыннан,дәүләт хакимияте яисә идарәсе,җирле хакимиятнең яисә идарәсенең органнары тарафыннан компенсация түләүләре керту юлы белән тиешле бюджетларга һәм бюджеттан тыш фондларга кертелә. Компенсация түләүләре әлеге Законның 56 статьясында каралган зыяннарны каплаудан тыш кертелә.

/3/ Җир асты байлыклары милекчесенең югалтуларын компенсацияләү белән бәйле бәхәсләр әлеге Законның 49 статьясында билгеләнгән тәртиптә хәл ителә.

## IX бүлек. Халыкара һәм дәүләтара шартнамәләр

### 58 статья. Халыкара һәм дәүләтара шартнамәләр

/I/ Әгәр Татарстан Республикасы катнашында төзелгән халыкара яисә дәүләтара шартнамәдә җир асты байлыклары турында Татарстан Республикасы законнарында каралмаган башка кагыйдәләр билгеләнгән булса, бу очракта халыкара яисә дәүләтара шартнамә

кагыйдәләре кулланыла.

Татарстан Республикасы Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1992 елның 25 декабре
№ 1722-XII